**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2022елның 10 октябре** **75-РС номер**

# К А Р А Р

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи айлык акчалата бүләк күләмнәрен арттыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи айлык акчалата бүләк күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 9 апрелендәге 25-РС номерлы « Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " карары белән расланган вазыйфаи айлык акчалата бүләк күләмнәрен 1,04 тапкыр арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларына карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 9 апрелендәге 25-РС номерлы « Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " карары белән билгеләнгән тәртиптә арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа оклады күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**